КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 26 май г.Казань № 375

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында» 2020 ел, 30 сентябрь, 887 нче карары белән расланган 2021 елга Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтүне тәэмин итүчеләр реестрына кертелгән, әмма социаль хезмәтләр күрсәтүгә бәйле рәвештә дәүләт заказын үтәүдә катнашмаучы дәүләткә карамаган оешмаларга компенсация түләүгә (чыгымнарны каплауга) Татарстан Республикасы бюджетында күздә тотыла торган акча күләмен билгеләү өчен кеше, койка-көннәр санына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында» 2020 ел, 30 сентябрь, 887 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 19 декабрь, 1159 нчы; 2021 ел, 27 гыйнвар, 28 нче; 2021 ел, 25 февраль, 95 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2021 елга Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтүне тәэмин итүчеләр реестрына кертелгән, әмма социаль хезмәтләр күрсәтүгә бәйле рәвештә дәүләт заказын үтәүдә катнашмаучы дәүләткә карамаган оешмаларга компенсация түләүгә (чыгымнарны каплауга) Татарстан Республикасы бюджетында күздә тотыла

торган акча күләмен билгеләү өчен кеше, койка-көннәр санына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Түбән Кама муниципаль районы» юлының 6 графасында «6 300» саннарын «8 400» саннарына алмаштырырга;

«Яр Чаллы шәһәре» юлында:

2 графада «Содействие» Владимирск социаль ярдәм күрсәтү үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасы» сүзләрен «Содействие» социаль хезмәт күрсәтү үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасы» сүзләренә алмаштырырга;

4 графада «4 360» саннарын «14 271» саннарына алмаштырырга;

6 графада «16 800» саннарын «18 480» саннарына алмаштырырга.

2. Бу карарның гамәле 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин